# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Сахаровка авыл җирлеге» Речное авыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**11.04.2024 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 11 апрелендә узган гражданнар җыенының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде, түбәндәге сорау буенча «Сез Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Сахаровка авылы җирлегенең Речное авылы торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану турындагы мәсьәлә буенча гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында» 2023 нче елның 14 нче ноябрендәге 1 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү белән килешәсезме,чараны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

--торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;
-торак пункт территориясен төзекләндерү;
- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү
-су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 197 кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 112 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«ЯКЛЫЙМ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 112 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Алексеевск муниципаль районы Сахаровка авыл җирлегендәге Речное авыл торак пунктында гражданнар җыены булып узды дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга: «Сез Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Сахаровка авылы җирлегенең Речное авылы торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану турындагы мәсьәлә буенча гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында» 2023 нче елның 14 нче ноябрендәге 1 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү белән килешәсезме,чараны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

-торак пункт территориясен төзекләндерү;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү

-су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Сахаровка авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Совет утырышында рәислек итүче,**
**Сахаровка авыл җирлеге**
**1 нче сайлау округы депутаты** **Н.И.Леденцов**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «САХАРОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА 1051124/18 СОВЕТ САХАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ